**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1695**
**06.04.2020**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 83638,17 мең сум: 2020 елда – 28165,24 мең сум; 2021 елда – 27712,46 мең сум; 2022 елда – 27760,47 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 нче «Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (мең сум) | 2021 ел (мең сум) | 2022 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 28165,24 | 27712,46 | 27760,47 | 83638,17 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2020-2022 елларга Программаны финанслау күләме 83638,17 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Барлык чорга 83638,17 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2020 елга – 28165,24 мең сум, 2021 елга – 27712,46 мең сум, 2022 елга – 27760,47 мең сум.»;

- 6 бүлекнең 2 нче бурычының 12, 13 пунктларын һәм «барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | «Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы» исеме бирелгән затларга айлык акчалата түләү | Шәһәр Башкарма комитеты | Ел дәвам ында | Кеше саны | 111 | 111 | 111 | 111 | 1533,06 | 1533,06 | 1533,06 |
| 13 | БВС ветераннарын, хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, төзүче-ветераннарны календарь бәйрәмнәр белән котлау | Шәһәр Башкарма комитеты | Ел дәвам ында | Кеше саны | 0 | 300 | 300 | 300 | 565,97 | 143,97 | 144,0 |
| барлыгы: | | | | | 1791 | 2092 | 2092 | 2092 | 3019,03 | 2597,03 | 2597,03 |

- 6 бүлекнең 3 нче бурычының 18, 19 пунктларын һәм «барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Иҗтимагый оешмалар активистларына материаль стимуллаштыру чаралары бирү:<br>- Ветераннар Советы;<br>- Инвалидлар җәмгыяте;<br>- Сукырлар җәмгыяте;<br>- Саңгыраулар җәмгыяте;<br>- Репрессиягә дучар булучылар җәмгыяте | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвам ында | Оешмалар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 697,2 | 619,2 | 619,2 |
| 19 | Иҗтимагый оешмаларның элемтә хезмәтләре, коммуналь түләүләре | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвам ында | Оешмалар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 92,83 | 92,83 | 92,83 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чыгымнарын компенсацияләү | | | | | | | | | | |
| барлыгы: | | | | | 2609 | 3149 | 3149 | 3149 | 1760,03 | 1682,03 | 1682,03 |

- 6 бүлекнең 6 нчы бурычының 25 пунктын һәм «барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 25 | Халыкны социаль яклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү. | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, «Хезмәт ветераннары өчен пансионат» МАУ | Ел дәвамында | Күрсәтелгән хезмәтләр саны | 200 | 200 | 200 | 200 | 3856,18 | 3856,18 | 3856,18 |
| барлыгы: | | | | | 200 | 200 | 200 | 200 | 3856,18 | 3856,18 | 3856,18 |

- 6 бүлекнең «барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барысы: | | | | 72670 | 73446 | 73446 | 73446 | 28165,24 | 27712,46 | 27760,47 |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов